**Республика Татарстан**
**Лаишевский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Орловского**
**сельского поселения**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Орлов**
**авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**

422629 ул. Олимпийская д.2 а, д. Орел,
Orel.La@tatar.ru, тел/факс 8(84378)4-49-10

р/с 40204810100000440016 ИНН 1624009334

**2024елның 29 ноябре** **15 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 16 апрелендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 16 апрелендәге 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Бирелгән ташламаларны түләүчеләр тарафыннан таләп ителгәнлекне бәяләүне уздыру максатларында, Башкарма комитет тарафыннан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин, бу очракта ташлама кирәк дип танылачак».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

**Башлык-Татарстан  Республикасы**
**Лаеш  муниципаль  районы  Орел**
**авыл  җирлеге Советы рәисе** **В.И. Фетилина**